| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БУТЛЕРОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БУТЛЕРОВКА АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.03.2019 с. Мокрые Курнали № 100

**Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы**
**Бутлеровка авыл җирлегендә**
**муниципаль хезмәт турындагы**
**Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Алексеевск районы прокуратурасының 30 гыйнвар, 2019 ел, 02-08-02 нче гаризасын үтәү йөзеннән, шулай ук гамәлдәге законнарга, шул исәптән "Коррупциягә каршы көрәшү турында"гы 25 декабрь, 2008 ел, 273-ФЗ санлы Федераль закон нигезләмәләренә туры китерү максатларында

**Бутлеровка авыл җирлеге Советы карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлегенең 25 июнь, 2018 ел, 73 нчы карары тарафыннан расланган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге эчтәлектәге үзгәреш кертергә.

12.1 пунктның 2 нче пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яки ышанычлы кешеләр аша шөгыльләнергә, коммерция оешмасына идарә итүдә яки коммерциячел булмаган оешмага идарә итүдә катнашырга (сәяси партиягә идарә итүдә, профессиональ берлек органына идарә итүдә бушлай нигездә катнашудан, шул исәптән җирле үзидарә органында булдырылган башлангыч профсоюз оешмасының сайлап куела торган органына идарә итүдә катнашудан, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында катнашудан; съездда (конференциядә) яки башка җәмәгать оешмасы, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәтләрендә катнашудан; бушлай нигездә күрсәтелгән коммерциячел булмаган оешмалар белән (сәяси партия һәм профсоюзлар берлеге органы, шул исәптән җирле үзидарә органында булдырылган башлангыч профсоюз оешмасының сайлап куела

торган органыннан, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратыннан тыш) бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында яки аларның идарәләренең яллаучы һәм (яки эш бирүче) вәкиленең муниципаль хокук актында билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән коллегиаль органына керүдән оештыручысы (акционер, катнашучы) муниципаль берәмлек булган идарә һәм оешманың ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен бушлай нигездә тәкъдим итүдән тыш оешманы оештыручының муниципаль вәкаләтләр берәмлеге яки муниципаль милектәге акцияләргә (устав капиталында катнашу өлешләре) идарә итү исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен билгеләүче муниципаль хокук актлары нигезендә муниципаль берәмлек булып торучы, федераль законнарда билгеләнгән башка очракларда;

12.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.4. Россия Федерациясе норматив хокук актларында билгеләнгән исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын башкаручы граждан муниципаль хезмәттән киткәннән соң ике ел дәвамында

хезмәт килешүе шартларында оешмада вазыйфа башкарырга һәм (яки) әлеге оешмада ай дәвамында гражданлык-хокукый килешү шартларында йөз мең сумлыктан артык бәяле эш (әлеге оешмада хезмәтләр күрсәтергә) башкарырга хокуклы, әгәр муниципаль хезмәткәрнең хезмәттә үз-үзен тотуына һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салуга таләпләрне үтәү буенча тиешле комиссия ризалыгы белән әлеге оешманың аерым муниципаль (административ) функцияләре муниципаль хезмәткәрнең хезмәт вазыйфасына керсә".

26.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"26.3. "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында"гы 2 март, 2007 ел, 25-ФЗ санлы Федераль законның 14.1, 15 һәм 27 нче маддәләрендә каралган шелтә белдерүләр Татарстан Республикасының норматив-хокук актлары һәм (яки) муниципаль хокук актлары тарафыннан билгеләнгән тәртиптә яллаучы (эш бирүче) вәкиле тарафыннан кулланыла:

1) Коррупция һәм башка хокук бозуларны булдырмау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад нигезендә;
2) әгәр тикшерү нәтиҗәләре турындагы доклад комиссиягә җибәрелсә, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәттә үз-үзләрен тотышына таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия тәкъдимнәре нигезендә;
3) Коррупция һәм коррупцион хокук бозулар турында башка хокук бозуларны булдырмау буенча тиешле муниципаль орган кадрлар хезмәте бүлекчәсе докладып (анда аның нинди хәлләрдә кылынуы бәян ителә) һәм муниципаль хезмәткәрнең аның ризалыгыннан башка гына язмача аңлатмасы нигезендә һәм ул коррупцион хокук бозуларны кылу фактын

тану шартларында (ышанычны югалтуы сәбәпле эштән азат итү рәвешендә шелтә кулланудан башка);

4) муниципаль хезмәткәрнең аңлатмалары нигезендә;

5) башка материаллар нигезендә».

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге Советының 16 ноябрь, 2018 ел, 88 нче карарын көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталында җирлек сайтында бастырырга һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Бутлеровка авыл җирлеге Советы бинасында махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземдә калдырам.

Алексеевск муниципаль районы
Бутлеровка авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе Ф.А.Хайрутдинова